КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 ноябрь г.Казань № 1006

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче; 2018 ел, 14 март, 151 нче; 2018 ел, 11 июнь, 461 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1139 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 2 июль, 525 нче; 2019 ел, 30 август, 735 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 859 нчы; 2020 ел, 28 гыйнвар, 31 нче; 2020 ел, 25 февраль, 141 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 830 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта «2 442,1» саннарын «2 515,3» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3 нче пунктында:

3.3.26 нчы пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.26. Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турындагы үтенечнамәләрне карап тикшерә, законнар белән билгеләнгән очракларда үтенечнамәләрне, карап тикшермичә, кире кайтаруны гамәлгә ашыра йә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турындагы карарлары проектларын йә үтенечнамәләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турындагы карарлар проектларын әзерли.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа 3.3.26[1] нче пунктча өстәргә:

«3.3.26[1]. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен җирләрнең бер категориясеннән икенче категориясенә күчерү турындагы, хосусый, муниципаль милектәге, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләрен, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү (законнар белән күздә тотылган очрактан тыш) турындагы үтенечнамәләрне карап тикшерә. Законнар белән билгеләнгән очракларда үтенечнамәләрне, карап тикшермичә, кире кайтаруны гамәлгә ашыра йә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турындагы яисә күчерүдән баш тарту турындагы карарлары проектларын әзерли.».

2. Бу карарның 1 нче пунктындагы икенче абзацы гамәле 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин